РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
МАЛОБУИНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР БУАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » июнь 2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының «Буа шәһәре» муниципаль
берәмлеге белән чиктәш җирдә «Татар
Буасы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе
буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү турында» 2023елның 30 маендагы 6-46 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карарына ярашлы рәвештә, Татар Буасы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «Татар Буасы авыл җирлеге» берәмлеге чикләре турындагы проектны гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашу хокукын үтәү максатыннан

**КАРАР БИРӘМ:**

1.Беркетелгән карта - схема нигезендә (кушымта), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне 2023 елның « 04 » июленә 11.00 сәгатьтә ТР, Буа районы, Татар Буасы авылы, Яшьләр урамы, 33А йорт адресы буенча ТР Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авыл мәдәният йортында уздырырга дип билгеләргә.

2.Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2023 елның « 03 » июленә кадәр ТР, Буа районы, Татар Буасы авылы, Яшьләр урамы, 33 А йорт адресы буенча, Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге башкарма комитетында +7(84374) 3-36-45 телефоны буенча кабул ителә.

3.Әлеге карар Татар Буасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш.:

-ТР, Буа районы, Татар Буасы авылы, Яшьләр урамы, 2А йорт;

- ТР, Буа районы, Татар Буасы авылы, Яшьләр урамы, 33А йорт.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми рәвештә бастырылган көннән башлап

законлы көченә керә, шулай ук «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Татар Буасы
авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Йосыпов

ТР Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең
2023 елның 08 июнендәге 3 номерлы карарына
кушымта

